**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ НЫРСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**
**Утыз жиденче утырыш дүртенче чакырылыш**

**25.12.2025 ел** **№ 6** **Олы Нырсы ав.**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 маендагы №89 номерлы «Җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советы карар итте,

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 маендагы №89 номерлы «Җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмә хакында» карарына (19.09.2018 ел №91; от 09.10.2018 ел №100; 20.12.2018 ел №110; 08.05.2019 ел №119; 29.08.2019 ел №122; 21.10.2022 ел №64, 16.12.2022 ел №72, 28.06.2024 ел №109, 28.04.2025ел.№130 карарлар редакциясендә) (алга таба текст буенча – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең кече төркем белгеченең вазыйфаи окладын 16 928 сум күләмендә расларга.».

1.2 Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советының 17.05.2018 ел № 89 карарына 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегендә даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Айлык акчалата түләү, сум |
|---|---|
| | 12 төркем |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 25 401 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 18 254 |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
ОлыНырсы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Гиниятов